## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

### Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Өшкәтә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“15” ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, 2021 елның 15 ноябрендә «Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Олы Өшкәтә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куаклар кисү);

2) янгын куркынычсызлыгы таләпләре буенча:

- Олы Өшкәтә авылында су коеларын урнаштыру һәм ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 46 (кырык алты) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 31 (утыз бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 31 (утыз бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2022 елда Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Олы Өшкәтә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куаклар кисү);

2) янгын куркынычсызлыгы таләпләре буенча:

- Олы Өшкәтә авылында су коеларын урнаштыру һәм ремонтлау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)" мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Өшкәтә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОГРН 1021606155405
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1610000476